ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль, 2016 ел № 6/5

2015 ел өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлаулар хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2015 ел өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү көнен 2016 елның 14 мартына, үткәрү вакытын 14 сәгатькә тәгаенләргә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.

2. 2015 ел өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү буенча комиссия составын кушымтадагыча расларга.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советы Карарына
кушымта
24 февраль, 2016 ел

2015 ел өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызы | - комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | - Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы; |
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары; |
| Хәйбуллина Евгения Александровна | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы. |